РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ
БОЛЬШЕКИБЯЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422065, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Большие Кибячи, ул.Ф.Энгельса, 21
тел. (84362) 42-6-24

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОЛЫ КИБӘЧЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422065, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Олы Кибәче авылы, Ф.Энгельс урам, 21 йорт

тел. (84362) 42-6-24

e-mail: Bkib.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ — КАРАР

23.09.2019 — № 16

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Олы Кибәче авыл җирлеге Советының
“Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Олы Кибәче авыл җирлеге Советы
Регламентын раслау турында” 23.12.2009 елгы №19а
карарына үзгәрешләр кертү турында

ТР Саба районы прокуратурасының 10.09.2019 елгы №02-01-20-19 хатына, Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Уставына туры китереп, Олы Кибәче авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Советының 23.12.2009 елгы №19а карары белән расланган Олы Кибәче авыл җирлеге Советы Регламентына түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. Регламентның 6 нчы бүлеген түбәндәге эчтәлекле 34.1 статья белән тулыландырырга:

“Статья 34.1:

1. Олы Кибәче авыл җирлеге башлыгы, район прокуроры, шулай ук Олы Кибәче авыл җирлеге Уставы, закончалык белән вәкаләтле вазыйфаи затлар, Советның ачык һәм ябык утырышларында катнашырга хокуклы.

2. Советның ачык утырышларында Олы Кибәче авыл җирлегендә яшәүчеләр һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнаша ала.

3. Совет тарафыннан аларның эшчәнлегенә караган сорауларны караганда, башкарма комитет эшчеләре ачык утырышларда катнашырга хокуклы.

4. Әгәр гомуми депутатларның күпчелеге тарафыннан хупланса, Совет җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының утырышта катнашуын таләп итәргә хокуклы.

Катнашу турында таләп, утырышка кадәр өч көннән дә соңга калмыйча, Совет утырышына чакырылучы вазыйфаи затка утырышның көне, вакыты, урыны, утырышка куелган сораулар турында Совет рәисе тарафыннан хәбәр ителергә тиеш.

5. Утырышны ачар алдыннан, Совет рәисе Совет депутатлары булып тормаучы, утырышта катнашучы затлар турында игълан итә.

6. Утырышка чакырылган һәм катнашучы затлар Совет эшенә тыкшынырга хокуклы түгел. (чыгыш ясарга, белдерү эшләргә, хуплау яки ризасызлык белдерергә)

7. Совет карары нигезендә, чакырылганнарга әлеге Регламент кысаларында чыгыш ясау өчен сүз бирелергә мөмкин.”

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/ kibiachi адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырырга.

9. Карар рәсми бастырып чыгарган көннән үз көченә керә.

10. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Олы Кибәче авыл җирлеге башлыгы: А. К. Сафин